РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 124

2018 елның 26 июне

# Түбән Кама шәһәрендә 2018-2019 еллар ягу чорына әзерлекне тикшерү программасын раслау турында

Россия Федерациясе энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы боерыгы белән расланган «Ягу чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләре»нең 5 нче пункты нигезендә, шулай ук 2018-2019 еллар ягу чорында тотрыклы һәм ышанычлы эшләүгә торак-коммуналь хуҗалык объектларын, җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре предприятиеләрен үз вакытында әзерләү максатыннан чыгып, карар бирәм:

1. 2018-2019 еллар ягу чорында эшләү өчен предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр буенча комиссия төзергә.
2. Җаваплы затлар белән килештереп (1 нче кушымта), 2018-2019 еллар ягу чорында эшләүгә предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләрне әзерләү буенча комиссия составын расларга.
3. 2018-2019 еллар ягу чорына әзерлекне тикшерү программасын расларга (2 нче кушымта).
4. Әлеге карарны «Нижнекамская Правда» газетасында бастырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче: Д.И. Баландин

Татарстан Республикасы
Түбән Кама шәһәре
башкарма комитетының
2018 елның 26 июнендәге
124 номерлы карары белән расланган
1 нче кушымта

Түбән Кама шәһәрендә 2018-2019 еллар ягу чорына әзерлекне
тикшерү комиссиясе составы:

| | | |
|---|---|---|
| Баландин Денис Иванович | - | Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Перепелов Павел Дмитриевич | - | «Түбән Кама шәһәренең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү департаменты» МУП директоры, комиссия рәисе урынбасары. |
| Комиссия члennары: | | |
| Салаватов Айрат Ринат улы | - | Ростехнадзорның Идел буе идарәсе Түбән Кама территориаль бүлеге башлыгы (килешенү буенча); |
| Төхвәтуллин Айрат Сәгыйть улы | - | Ростехнадзорның Идел буе идарәсе Түбән Кама территориаль бүлегенең газ бүлү һәм газ куллану челтәрләренә күзәтчелек буенча дәүләт инспекторы; |
| Вафин Рамил Шәфкать улы | - | Ростехнадзорның Идел буе идарәсе Түбән Кама территориаль бүлегенең җылылык-энергия җайланмаларын һәм челтәрләрен күзәтү буенча дәүләт инспекторы; |
| Вафин Радиф Шәфкать улы | - | Ростехнадзорның Идел буе идарәсе Түбән Кама территориаль бүлегенең электр энергиясе җайланмаларын күзәтү буенча дәүләт инспекторы; |
| Слободюк Константин Петрович | - | ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсе башлыгы (килешенү буенча); |
| Ихсанова Наилә Нариман кызы | - | Түбән Кама зонасы торак инспекциясе башлыгы (килешенү буенча); |
| Красильников Василий Борисович | - | «Татэнергсбыт» акционерлык җәмгыяте филиалының Кама бүлеге җитәкчесе (килешенү буенча); |
| Гәрәев Айдар Фердинант улы | - | «Татэнерго» АҖ филиалы - «Түбән Кама җылылык челтәрләре» директоры; |
| Нуртдинов Илдар Наил улы | - | «Су үткәрү-канализация һәм энергетика хуҗалыгы» АҖ генераль директоры (килешенү буенча). |

Татарстан Республикасы
Түбән Кама шәһәре
башкарма комитетының
2018 елның 26 июнендәге
124 номерлы карары белән расланган
2 нче кушымта

Түбән Кама шәһәрендә 2018/2019 еллар ягу чорына әзерлекне
тикшерү программасы

1. Гомуми нигезләмәләр

Торак-коммуналь хуҗалык объектларының эшләвенең ышанычлылыгын тәэмин итү, ягу чорына үз вакытында һәм төрле яклап әзерләнү һәм кулланучыларны тотрыклы җылылык, су, электр, газ һәм ягулык белән тәэмин итүгә ирешү, энергия чыганакларының кирәкле параметрларын саклап калу һәм аларның билгеләнешен һәм торак-коммуналь хезмәтләрне кулланучыларның түләү дисциплинасын исәпкә алып, биналарда норматив температура режимын тәэмин итү максатларында, аны оешкан төстә үткәрү җирле үзидарә органнарының, торак-коммуналь хуҗалык оешмаларының мөһим бурычы булып тора.

Торак-коммуналь хуҗалык объектларын ягу чорына әзерләү, температура һәм башка һава факторларының аларның эшләренең ышанычлылыгына йогынтысын булдырмау, нормадан тыш тузуны һәм сафтан чыгуын кисәтү, шулай ук ягу чорында халыкның таләп ителгән тереклек эшчәнлеге шартларын һәм коммуналь инфраструктурасы системасының эш һәм биналарны инженер-техник яктан тәэмин итү режимнарын тәэмин итү максатларында үткәрелә.

Торак-коммуналь хуҗалык объектларын ягу чорына әзерләү тәэмин итәргә тиеш:

- торак-коммуналь хуҗалык объектларын норматив техник эксплуатацияләү, биналарда билгеләнгән температура-дымлылык режимын, халыкның санитария-гигиена шартларын үтәү;

- торак-коммуналь хуҗалык объектларының максималь ышанычлылыгы һәм экономиялелеге;

- торак фонды һәм социаль өлкә биналары, коммуналь корылмалар җиһазларының төзелеш конструкцияләре һәм инженер-техник тәэмин итү системаларының норматив хезмәт срокларын үтәү;

- матди-техник чараларны һәм ягулык-энергетика ресурсларын рациональ файдалану.

Торак-коммуналь хуҗалык объектларын ягу чорына үз вакытында һәм сыйфатлы әзерләүгә ирешелә:

- вазыйфаи затлар тарафыннан федераль һәм өлкә законнары таләпләрен, муниципаль норматив хокукый актларны, торак-коммуналь хуҗалык объектларын эксплуатацияләү кагыйдәләрен, кулланмаларын һәм инструкцияләрен үтәү белән;

- төзелеш, капиталь һәм агымдагы ремонт планнары, шулай ук торак-коммуналь хуҗалык объектларына техник хезмәт күрсәтү буенча проект-смета документациясен эшләү һәм үтәү белән;

- техник торышын даими контрольдә тоту, барлык төр планлы-кисәтү тикшерүләре уздыру, шулай ук аварияләр һәм җитешсезлекләр барлыкка килү сәбәпләрен җентекләп анализлау һәм ремонт-торгызу эшләренең кирәкле күләмен билгеләү белән;

- төгәл оештыру һәм билгеләнгән срокларда һәм кирәкле сыйфат белән ремонт-торгызу эшләрен башкару, бурычларны кую һәм ремонт-торгызу эшләренә йомгак ясауның нәтиҗәле системасы белән;

- торак-коммуналь хуҗалык оешмаларын йөкләнә торган бурычларны хәл итүне тәэмин итә торган дәрәҗәгә кадәр әзерләнгән эксплуатацияләү һәм эксплуатация-ремонт персоналы белән комплектлау белән;

- ремонтлау-торгызу эшләренең матди-техник тәэмин ителеше, эксплуатация ихтыяҗларына, фондка капиталь һәм агымдагы ремонт ясауны кирәкле максатчан финанслау, матди ресурслардан рациональ файдалануны тәэмин итү белән;

- ягу чоры башланыр алдыннан оештыру-техник чараларны, җиһазларны тикшерү һәм сынаулар комплексын тулысынча үтәү белән.

2. Ягу чорына әзерлекне тикшерү буенча комиссия эше

2.1. Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты оештыра:

- җылылык белән тәэмин итү чыганакларының, үзәк җылылык пунктларының, муниципаль берәмлекләрнең җылылык челтәрләренең һәм гомумән җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның ягу чорына әзерлеген тикшерү буенча комиссия эшен;

- торак-коммуналь хуҗалык һәм социаль өлкә объектларының җылылык чорына әзерлеген тикшерү буенча комиссия эшен;

- торак фондының җылылык кабул итүгә, коммуналь корылмаларның ягу чорына әзерлеген, коммуналь объектларның һәм авария бригадаларының дежур сменаларының әзерләнгән һәм аттестацияләнгән персонал белән тәэмин ителешен, аларның азаймый торган ТМС запасы, ягулык һәм химик реагентлар белән тәэмин ителешен тикшерүне.

Җылылык белән тәэмин итү чыганакларының, үзәк җылылык пунктларының, муниципаль берәмлекләрнең җылылык челтәрләренең һәм тулаем җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның ягып җылыту чорына әзерлеген бәяләү Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә расланган комиссия тарафыннан 15 сентябрьдән дә соңга калмыйча билгеләнә.

Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган комиссия тарафыннан, 15 сентябрьдән дә соңга калмыйча, җылылык белән тәэмин итү чыганакларының, үзәк җылылык пунктларының, муниципаль берәмлекләрнең җылылык челтәрләренең һәм гомумән җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның ягу чорына әзерлеге бәяләнә.

Комиссия Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.

Комиссия эше ягу чорына әзерлекне тикшерү графигы (1 нче таблица) нигезендә гамәлгә ашырыла, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

- тикшерелергә тиешле объектлар;
- тикшерү уздыру сроклары;
- тикшерү барышында тикшерелә торган документлар.

1 нче таблица

Ягу чорына әзерлекне тикшерү графигы

| № п/п | Тикшерелергә тиешле объектлар | Объектлар саны | Тикшерү үткәрү сроклары | Тикшерү барышында тикшерелә торган документлар |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Җылылык-челтәр оешмалары:<br>а) «Су үткәрү-канализация һәм энергетика хуҗалыгы» АҖ<br>б) «Татэнерго» АҖ филиалы - «Түбән Кама җылылык челтәрләре» | 2 | 01.06.2018-01.09.2018 | 3 нче кушымта нигезендә |
| 2. | Түбән Кама шәһәренең торак фонды | 819 | 01.06.2018-01.09.2018 | 4 нче кушымта нигезендә |
| 3. | Шул исәптән: күпфатирлы йортлар | 792 | | |
| 4. | ведомство торагы | 17 | | |
| 5. | Түбән Кама шәһәренең социаль объектлары | 236 | | |

Тикшерү вакытында комиссияләр тарафыннан 2018/2019 еллар ягу чорына әзерлекне тикшерү әлеге программасының 3,4 нче кушымталары белән билгеләнгән таләпләрнең үтәлеше тикшерелә (алга таба – Программа).

Җылылык челтәре һәм җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан РФ Энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы боерыгы белән расланган ягу чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләре белән билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерү (алга таба – Кагыйдәләр) җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә техник регламентлар һәм башка норматив хокукый актлар белән билгеләнгән тиешле мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча комиссияләр тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Техник регламентларның яисә кагыйдәләр белән билгеләнгән таләпләргә карата җылылык белән тәэмин итү өлкәсендәге башка норматив хокукый актларның мәҗбүри таләпләре булмаган очракта, комиссияләр, ягу чорына әзерлек тәртибен җайга сала торган, тикшерелергә тиешле оешмаларның локаль актларының үтәлешен тикшерне гамәлгә ашыралар.

2.2. Тикшерү үткәрү максатларында комиссиянең әзерлек таләпләренең үтәлешен раслый торган документлар карала, ә кирәк булганда тикшерү объектларын карыйлар.

Тикшерү нәтиҗәләре ягу чорына әзерлекне тикшерү акты (алга таба – акт) белән рәсмиләштерелә, ул әлеге кагыйдәләрнең 1 нче кушымтасы нигезендә тәкъдим ителә торган үрнәк буенча тикшерү тәмамланганнан соң бер көннән дә

соңга калмыйча төзелә.

Актта тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссиянең түбәндәге нәтиҗәләре бар:

- тикшерү объекты ягу чорына әзер;

-тикшерү объекты, билгеләнгән вакытка комиссия тарафыннан бирелгән әзерлек таләпләренә кисәтүләрне бетерү шарты белән, ягу чорына әзер булачак;

- тикшерү объекты ягу чорына әзер түгел.

Комиссиянең әзерлек таләпләрен үтәүгә карата кисәтүләре булганда яисә әзерлек таләпләрен үтәмәгәндә, актка. аларны бетерү срокларын күрсәтеп, кисәтүләр исемлеге (алга таба – Исемлек) теркәлә.

Әгәр тикшерү объекты ягу чорына әзер булса, шулай ук комиссия биргән әзерлек таләпләренә кисәтүләр исемлектә билгеләнгән срокта бетерелгән очракта, ягу чорына әзерлек паспорты (алга таба – паспорт) әлеге программаның 2 нче кушымтасында тәкъдим ителгән үрнәк буенча төзелә һәм акт имзаланган көннән 15 көн эчендә һәр объект буенча комиссия тарафыннан бирелә.

Паспортларны бирү сроклары климат шартларының үзенчәлекләренә карап, 15 сентябрьдән дә соңга калмыйча – җылылык энергиясен кулланучылар өчен, 1 ноябрьдән дә соңга калмыйча – җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмалары өчен, 15 ноябрьдән дә соңга калмыйча – муниципаль берәмлекләр өчен, комиссия рәисе (рәис урынбасары) тарафыннан билгеләнә.

Әлеге программаның 1 нче таблицасында билгеләнгән срокта әзерлек таләпләрен үтәүгә (үтәмәүгә) Исемлектә күрсәтелгән кисәтүләр бетерелгән очракта, комиссия кабат тикшерү үткәрә, аның нәтиҗәләре буенча яңа акт төзелә.

Тикшерү объектлары буенча әлеге Программаның 1 нче таблицасында билгеләнгән көнгә кадәр әзерлек паспорты алмаган оешма җылыту чорына әзерлекне дәвам итәргә һәм әзерлек буенча таләпләрне үтәүгә (үтәмәүгә) актка Исемлектә күрсәтелгән кисәтүләрне бетерергә тиеш. Комиссиягә әзерлек буенча таләпләрне үтәүгә (үтәмәүгә) кимчелекләрне бетерү турында хәбәр иткәннән соң кабат тикшерү үткәрелә. Комиссия уңай бәяләмә биргән очракта, ягу чорына әзерлек турында нәтиҗә белән кабат акт рәсмиләштерелә, әмма агымдагы ягу чорына паспорт бирелми.

3. Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмаларының, җылылык энергиясен кулланучылар, аларның җайланмалары комиссия белән җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтырылган:

1. Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмалары «Түбән Кама шәһәренең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү департаменты» муниципаль унитар предприятиесенә (алга таба – ТКХ департаменты) 3 нче кушымтада күрсәтелгән әзерлек таләпләрен үтәү буенча мәгълүмат тапшыралар.

Комиссия программаның 2.2 пункты нигезендә әзерлек таләпләрен үтәүне раслаучы документларны карый.

2. Җылылык энергиясен кулланучылар җылылык белән тәэмин итүче оешмага 4 нче кушымтаның 2, 5, 8 нче пунктларында күрсәтелгән әзерлек таләпләрен үтәү буенча мәгълүмат тапшыралар. Кулланучылар, 4 нче кушымтаның 1, 3, 4, 9, өлешчә 10, 15, 17 пунктларында күрсәтелгән таләпләрнең үтәлеше буенча мәгълүматны комиссия таләбе буенча карауга ТКХ департаментына мөстәкыйль рәвештә

тапшыралар.

Җылылык белән тәэмин итүче оешма кулланучыларның җылылык энергиясен исәпкә алу төеннәрен эксплуатацияләүгә кертүне гамәлгә ашыра, җылылык пунктларының тыгызлыгы һәм ныклыгы өчен җиһазларын сынаганда, теплофикация суы белән җылылык файдалану системаларын гидропневамтик юдырганда катнаша һәм тикшерү объектларын карап чыга.

Җылылык белән тәэмин итүче оешма 2018/2019 еллар ягу чорына әзерлекне тикшерү актын рәсмиләштерә һәм аны ТКХ департаментына комиссия каравына җибәрә.

Атна саен пәнҗешәмбе көннәрендә җылылык белән тәэмин итүче оешма ТКХ департаментына кулланучылар объектларын ягу чорына әзерләү буенча белешмә рәвешендә мәгълүмат бирә.

Комиссия Программаның 2.2 пункты нигезендә әзерлек таләпләрен үтәүне раслаучы документларны карый.

1 нче кушымта

2018/2019 еллар ягу чорына әзерлекне тикшерү
____ номерлы АКТЫ

___________________________ «_____»____________ 20__ ел
(акт төзү урыны) (акт төзү вакыты)

_________________________________________________________________расланган
(Ягу чорына әзерлекне тикшерүче орган җитәкчесенең (аның ярдәмчесенең) ФИА ис.)
20___ елның «____»________________ ягу чорына әзерлекне тикшерү Программасы нигезендә ______________________________________________ төзелгән комиссия
(комиссия төзелгән документ формасы һәм аның реквизитлары)
«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә
20__ елның «___»____________ нән 20__елның «___»_____________ кадәр
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
(аңа карата ягу чорына әзерлекне тикшерү үткәрелгән муницииипаль берәмлекнең, җылылык белән тәэмин итүче оешманың, җылылык челтәре оешмасының, җылылык энергиясен кулланучының тулы исеме)
ягу чорына әзерлекне тикшерде.
Ягу чорына әзерлекне тикшерү түбәндәге объектларга карата үткәрелде:

1.______________________________________________________;
(объектның исеме, мәйданы, мең кв. м)

2.______________________________________________________;
(объектның исеме, мәйданы, мең кв. м)

3.______________________________________________________;
(объектның исеме, мәйданы, мең кв. м)

Ягу чорына әзерлекне тикшерү барышында комиссия билгеләде: _________________________________________________________________.
(ягу чорында эшкә әзер булу/әзер булмау)

Ягу чорына әзерлекне тикшерү буенча комиссия нәтиҗәсе:
___________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

Ягу чорына әзерлекне тикшерү актына кушымта _ _ / _ _ел.*

Комиссия рәисе: ___________________/_______________
(имза, имзаны расшифровкалау)

Рәис урынбасары

комиссияләре: ______________________/_________________

(имза, имзаны расшифровкалау)

Комиссия әгъзалары: ______________________/_________________

(имза, имзаны расшифровкалау)

______________________/_________________

(имза, имзаны расшифровкалау)

Әзерлекне тикшерү акты белән таныштым, актның бер нөсхәсен алдым:

«___»____________20__ел__________________________________________________________

(аңа карата ягу чорына әзерлекне тикшерү үткәрелгән муниципаль берәмлек башлыгы (аның вәкаләтле вәкиле), җылылык белән тәэмин итүче оешма, җылылык челтәре оешмасы җитәкчесе, җылылык энергиясен кулланучы имзасы, имзасын расшифровкалау)

җылыту чорына әзерлекне тикшерү.
Ягу чорына әзерлекне тикшерүнең
20__ елның «_____»________________ ___ номерлы актына
әзерлек буенча таләпләрне үтәүгә яки таләпләрне үтәмәгәндә кисәтүләр Исемлеге

1.______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Кимчелекне бетерү вакыты -______________________
(дата)

2.______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Кимчелекне бетерү вакыты -______________________
(дата)

3.______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Кимчелекне бетерү вакыты -______________________
(дата)

2 нче кушымта

________/________ еллар ягу чорына әзерлек
паспорты

Ягу чорына әзерлекне тикшерү үткәрелгән түбәндәге объектларда карата:
1.___________________________;
2.___________________________;
3.___________________________;
___________________________________________________________________________бирелде.
(аңа карата ягу чорына әзерлекне тикшерү үткәрелгән муниципаль берәмлекнең, җылылык
белән тәэмин итүче оешманың, җылылык челтәре оешмасының, җылылык энергиясен кулланучының тулы исеме)
Ягу чорына әзерлек паспортын бирү нигезе:
Ягу чорына әзерлекне тикшерү акты _____________ №_____________
__________________________/____________________________
(ягу чорына әзерлекне тикшерү буенча комиссия төзегән вәкаләтле органның имзасы, имзасын расшифровкалау һәм мөһере)

3 нче кушымта

Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмалары өчен ягу чорына әзерлек буенча таләпләр

Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмаларының ягу чорына әзерлеген бәяләү максатларында, вәкаләтле орган тарафыннан әлеге оешмаларга карата түбәндәгеләр тикшерелергә тиеш:

1) җылылык белән тәэмин итү турында Законда билгеләнгән тәртиптә төзелгән җылылык белән тәэмин итү системасы белән идарә итү турында килешү булу;

2) җылылык йөкләнешләре графигын үтәргә, җылылык белән тәэмин итү схемасы белән расланган температура графигын сакларга әзер булу;

3) техник регламентлар белән билгеләнгән җылылыкны тәэмин итүнең ышанычлылык критерийларын үтәү;

4) җылылык энергиясе чыганакларында норматив ягулык запаслары булу;

5) эксплуатацион, диспетчерлык һәм авария хезмәтләренең эшләве:

- күрсәтелгән хезмәтләрнең персонал белән тәэмин ителеше;

- персоналны индивидуаль һәм коллектив саклану чаралары, махсус кием, инструментлар һәм эшләр башкару өчен кирәкле җиһазлар белән тәэмин итү,

- норматив-техник һәм оператив документлар, инструкция, схемалар,

- беренчел янгын сүндерү чаралары.

6) үзләренеке булган җылылык челтәрләрен көйләү;

7) җылылык энергиясен куллану режимын контрольдә тотуны оештыру;

8) җылылык энергиясен тапшыру сыйфатын тәэмин итү;

9) сатып алына торган һәм гамәлгә ашырыла торган җылылык энергиясен коммерциячел исәпкә алуны оештыру;

10) алар карамагындагы җылылык челтәрләре төзелешенең сыйфатын тикшерүне, шул исәптән, җылылык белән тәэмин итү турындагы закон нигезендә, төзелештә кулланыла торган эшләргә һәм материалларга гарантияләр бирүне тәэмин итү;

11) җылылык белән тәэмин итү объектларының һәлакәтсез эшләвен һәм җылылык энергиясен кулланучыларны ышанычлы җылылык белән тәэмин итү, аерым алганда:

- ягулык кабул итү һәм бушату, ягулык әзерләү һәм ягулык белән тәэмин итү системаларының әзерлеге;

- су-химия режимын үтәү;

- эксплуатация срогын озайту буенча тиешле оештыру-техник чаралар үткәрмичә, ресурстан тыш җылылык энергетика җиһазларын файдалану фактлары булмау;

- җылылык чыганакларының җылылык егәрлеге һәм җылылык челтәрләренең үткәрү сәләте кытлыгы булганда җылылык белән тәэмин итүне чикләүнең расланган графигы булу;

- торак йортларны җылылык белән тәэмин итүдә авария хәлендәге кимчелекләрне бетерү өчен рөхсәт ителгән вакыт хисаплары булу;

- җылылык, электр, ягулык һәм су белән тәэмин итү оешмаларының, җылылык энергиясен кулланучыларның, ремонт-төзелеш һәм транспорт оешмаларының, шулай ук җирле үзидарә органнарының үзара бәйләнешен исәпкә алып, җылылык белән тәэмин итү системаларында аварияне бетерү тәртибе булу;

- җылылык челтәрләренең гидротехник һәм җылылык сынауларын үткәрү;

- җылылык белән тәэмин итүдә катнашучы җайланмаларга кирәкле техник тикшерү һәм диагностика үткәрүне үз эченә алган ягу чорында эшкә әзерлекнең расланган планын үтәү;

- җылылык челтәрләрен һәм җылылык энергиясе чыганакларын ремонтлауның план графигын үтәү;

- ягулык белән тәэмин итү өзеклекләренә юл куймый торган һәм ягулык запасларының билгеләнгән нормативларын киметмәүче ягулык белән тәэмин итүгә шартнамәләр булу;

12) җылылык энергиясен кулланучылар, җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмалары арасында эксплуатацион җаваплылыкны чикләүне билгеләүче документлар булу;

13) дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле дәүләт хакимияте органнары һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән ягу чорында эшнең ышанычлылыгына йогынты ясый торган билгеләнгән вакытта үтәлмәгән күрсәтмәләрнең булмавы;

14) булган очракта, автоматик көйләгечләрнең эшләве.

Җылылык һәм электр энергиясе җитештерү объектларына карата катнаш эшләп чыгару режимында бары тик электр энергетикасы турындагы закон нигезендә ягу сезонына әзерлек турындагы документның булуы гына тикшерелә.

Аларны үтәмәгәндә, җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмаларына карата, кисәтүләрне бетерү срокларын күрсәтеп, Исемлек кушымтасы белән акт төзелә торган шартларга әлеге 3 нче кушымтаның 1, 7, 9 һәм 10 пунктларында күрсәтелгән таләпләрне үтәмәү керә.

4 нче кушымта

Җылылык энергиясен кулланучыларга ягу чорына әзерлек буенча таләпләр

Җылылык энергиясен кулланучыларның ягу чорына әзерлеген бәяләү максатларында, вәкаләтле орган тарафыннан тикшерелергә тиеш:

1) җылылык энергиясе җайланмаларының җылылык һәм гидравлик эш режимнарында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә ачыкланган бозуларны бетерү;

2) җылылык кулланучы җайланмаларның җиһазларын һәм коммуникацияләрен юдыру;

3) эксплуатация режимнарын, шулай ук аларны гамәлгә кертү буенча чаралар эшләү;

4) ремонт планын үтәү һәм аларны үтәү сыйфаты;

5) җылылык энергиясен кулланучыга караган җылылык челтәрләренең торышы;

6) биналарның (чарлаклар, баскычлар, подваллар, ишекләр) һәм үзәк җылылык пунктларының, шулай ук индивидуаль җылылык пунктларының җылыту торышы;

7) җылылык пунктлары чикләрендә торба үткәргечләренең, арматураның һәм җылылык изоляциясенең торышы;

8) хисап приборларының булуы һәм эшләве, алар булганда, автоматик көйләгечләрнең эшләве;

9) җылылык куллану системаларын саклауның эшләве;

10) җылылык куллану корылмалары паспорты, хезмәт күрсәтүче персонал өчен принципиаль схемалар һәм инструкцияләр булу һәм аларның дөреслеккә туры килүе;

11) су үткәргеч һәм канализация белән җылылык пунктлары җиһазларының туры тоташуы булмау;

12) җылылык пунктлары җиһазларының тыгызлыгы;

13) исәп-хисап шайбаларында һәм элеваторлар соплосында пломба булу;

14) китерелгән җылылык энергиясе (егәрлек), җылылык үткәргеченә бурычлары булмау;

15) җылылык куллана торган җайланмаларны тиешенчә эксплуатацияләү өчен шәхси һәм (яки) җәлеп ителгән ремонт бригадаларының булуы һәм аларны матди-техник ресурслар белән тәэмин итү;

16) җылылык куллану җайланмаларының тыгызлыгын һәм ныклыгын билгеләүгә сынаулар үткәрү;

17) «Ягу чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында» РФ Энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы боерыгының 3 кушымтасында китерелгән критерийлар нигезендә, климат шартларын исәпкә алып, җылылык энергиясен кулланучыларны җылылык белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы.

Аларны үтәмәгәндә, җылылык энергиясен кулланучыларга карата, кисәтүләрне бетерү срокларын күрсәтеп, Исемлек кушымтасы белән акт төзелә торган шартларга әлеге 4 нче кушымтаның 8, 13, 14 һәм 17 пунктларында күрсәтелгән таләпләрне үтәмәү керә.